РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЕРХНЕЛАЩИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЮГАРЫ ЛАШЧЫ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2020 елның 22 мае 4нче номерлы

Буа муниципаль районы Югары Лачшы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 17 июле 6нчы номерлы карары белән расланган "Җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ирекле (волонтерлык) эшчәнлекне оештыручылар, ирекле ( волонтерлык) оешмалары белән үзара хезмәттәшлеге тәртибе"нә үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы «Хәйрия эшчәнлеге һәм иреклелек (волонтерлык) турында» Федераль законның 17.3 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Буа муниципаль районы Югары Лачшы авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Буа муниципаль районы Югары Лачшы авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган «Җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ирекле (волонтерлык) эшчәнлекне оештыручылар, ирекле (волонтерлык) оешмалары белән хезмәттәшлеге тәртибе»нә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Тәртипнең 5 пунктын киләсе редакциядә үзгәртергә һәм расларга: «Ирекле эшчәнлекне оештыручы, ирекле оешма үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру максатларында дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, учреждениеләргә һәм (яки) оешмаларга, кертемнәр тасвирламасы белән яисә "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша электрон документ рәвешендә, ирекле эшчәнлекне оештыру өлешендә хезмәттәшлек итү нияте турында тәкъдим (алга таба-тәкъдим) юллыйлар, ул түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

а) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), әгәр ирекле эшчәнлекне оештыручы булып физик зат торса;

б) оешма җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) һәм аның вәкиленең контактлары (телефон, электрон почтасы, адресы), әгәр ирекле эшчәнлекне оештыручы юридик зат булса;

в) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында булган дәүләт теркәү номеры;

г) "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайт яисә рәсми бит адресы турында мәгълүмат (булганда);

д) ирекләләр (волонтерлыкны) үстерү өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында булган идентификацион номер (булган очракта);

е) "Хәйрия эшчәнлеге һәм иреклелек (волонтерлык) турында" Федераль законның 2 статьясындагы 1 пунктында каралган максатларда ирекләләр тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эш төрләре (хезмәт күрсәтүләр) исемлеге (алга таба - Федераль закон), ул аларны күрсәтү шартларын, шул исәптән эш (хезмәт күрсәтү) срокларын һәм күләмнәрен, волонтерларның (волонтерларның) әзерлек дәрәҗәсен, компетенциясен, белем дәрәҗәсен һәм һөнәри күнекмәләрен, ирекләләр эшчәнлеген оештыручының

тиешле эшчәнлеге тәҗрибәсе, ирекле оешма тәҗрибәсен һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән башка таләпләрне тасвирлый.».

2. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча http://buinsk.tatarstan.ru урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ТР Буа муниципаль районы
Югары Лачшы авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Г.Х. Усманова